ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме тугызынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме тугызынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 40361-8 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында.
3. 2021 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында доклад.
4. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру турында».
5. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 264-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 259-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 265-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.
9. «Россия Федерациясе тимер юл транспорты уставы» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 43217-8 номерлы федераль закон проекты хакында («йөрт һәм түлә» шартларында тимер юл транспортында йөртүгә шартнамәләр төзү турында).

10. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.17[1] статьясына үзгәреш кертү хакында» 28683-8 номерлы федераль закон проекты турында (алкоголь продукциясен һәм спиртлы продукцияне сату өлкәсендә административ җаваплылыкны төгәлләштерү хакында).

11. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 41446-8 номерлы федераль закон проекты турында (йорт хайваннарын тоту таләпләрен үтәмәгән өчен административ җаваплылык билгеләү максатларында).

12. «Көнкүреш билгеләнешендәге пиротехник эшләнмәләрне куллану куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 46601-8 номерлы федераль закон проекты хакында.

13. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 51079-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт оборона заказы буенча продукция бәясе хакында тәкъдим һәм аны җитештерү чыгымнары турында мәгълүмат бирмәгән өчен җаваплылык билгеләү хакында).

14. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 42172-8 номерлы федераль закон проекты турында (кече һәм урта эшкуарлык субъектларына административ җәза билгеләүне камилләштерү өлешендә).

15. «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыруга чыгымнарны финанслашу өлешендә үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Владимир өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең мөрәҗәгате хакында.

16. «Пычраткыч матдәләр калдыкларын квоталау буенча тәҗрибә үткәрү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына атмосфера һавасын пычратуны киметү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 45652-8 номерлы федераль закон проекты хакында (федераль башкарма хакимият органнары вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә).

17. «Этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 16 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 555-8 номерлы федераль закон проекты хакында (алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмаларга шушы продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган

территорияләр чикләрен билгеләү турында хәбәр итү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

18. «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 57343-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт преференцияләре һәм муниципаль преференцияләр бирү максатлары өлешендә).

19. «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча тәҗрибә үткәрү турында» Федераль законның 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 43000-8 номерлы федераль закон проекты турында (салым органында һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куелу тәртибен камилләштерү хакында).

20. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $179^4$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 48712-8 номерлы федераль закон проекты хакында (шәһәр рельслы транспорт инфраструктурасын модернизацияләү эшләрен финанслау чыганагы белән тәэмин итү юлы ярдәмендә шәһәр рельслы транспорт инфраструктурасын яңартуны һәм үстерүне кызыксындыру өлешендә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 3 феврале
№ 1309- VI ДС